Минһаҗева, З. "Кемдер эчә, кемдер тарта, ә мин акчамны чәчәкләргә тотам" / З. Минһаҗева; [әңгәмәдәш] Г. Шиһапова // Шәһри Чаллы. – 2025. – №51 (18 июль). – Б. 6.

# Зөләйха Минһаҗева: «Кемдер эчә, кемдер тарта, ә мин акчамны чәчәкләргә тотам»



Гүзәл Шиһапова

**Редакциягә кунакка килгәч, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, шәһәрдәшебез Зөләйха Минһаҗева бакчасы турында сөйләп алган иде. Җай табып шунда барып кайттык. Уңган кешенең бакчасында гына түгел, капка төбендә үк чәчәкләр үсә. Ишегалды да гөлләргә күмелгән.**



«Әле Әҗмәкәйгә күченеп ике кыш кына чыктык, 10 ел элек Габидулла Хөрмәтуллинга кунакка килгәч бик кызыгып кайткан идем үз йортыма. «Монда буш участок бар, ал соң», – дигән иде ул. Озак уйлап тормыйча, тиз генә җир алып куйдык. Төзелеш калдыклары ята иде территориядә, алабута баскан иде. Күргән кешеләр бу җирне эшкәртеп бетерә алмассың дип борчылдылар», – ди Зөләйха Минһаҗева. Ә хәзер исә бу участок чәчәкләргә күмелгән. Биредә аларның төрләре 100 гә якындыр. Күпме хезмәт һәм акча кергәне күренеп тора, монда барлык үсентеләр дә сортлы, кыйммәтле. «Кемдер эчә, кемдер тәмәке тарта. Мин эчмим дә, тартмыйм да, акчамны шул бакчага тотам. Үзеңә ошаган нәрсәгә дә тотмагач ник кирәк ул акча? Үсемлекләрем чәчәк аткан-да күпме рәхәтлек алам. Мин үсентеләрне бары тик питомниклардан гына алам. Берсендә кулдан 10 төсле лилияләр сатып алган идем, рәсемнәре дә бар иде. Утырткач барысы да сары төсле булып чыкты, алдандым», – ди бакчачы. Танышлардан алмыйсызмы дип сорагач «Аларда миндә булмаган үсемлек юк инде хәзер, мин ала да, сата да белмим, бирә һәм тарата гына беләм. Бер биргәнем дә миңа бишләтә кайта аннары», – дип җавап бирде Зөләйха апа.

«Гортензияләрне бик яратам, менә бу «анабель», монысы «лайм лайт» дип атала. Аларны тамырландырам да сораучыларга таратам. Гортензияне кисеп алгач 15 минут эчендә корневинга тыгарга кирәк, алайса китми. Менә монда язда баштан спирея чәчәккә күмелә, аннан жасмин, аннан гортензиягә чират җитә. Шулай бер-берсен чиратлаштырып чәчәк атып торсыннар дигән исәп белән утыртам мин. Күпьеллыклар да, берьеллыклар да бар. Пеларгонияләрне орлыктан утырттым. Розаларны тамырландырам. Юбилейга биргән чәчәкләрне дә тамырландырдым. Вазада чәчәге шиңгәч кисеп алам да астагы ике бөрегә корневин сөртәм, өстә ике бөресен калдырып туфракка тыгып куям. Үсенте тамыр җибәргәнче каплап торырга кирәк, алайса кибә. Мин 5 литрлы шешәнең төбен кисеп шуның белән каплыйм. Үрмәле розам да бар, ул шундый хуш исле. Розаларның шиңгән чәчәкләрен гел өзеп торырга кирәк, аның урынына яңалары чыгып тора», – дип серләре белән бүлеште бакчачы.

«Мин алар белән сөйләшеп йөрим. «Чирлисеңме, түз, терелтәм», дим бер флоксыга. Шундый шәмәхә булып үсә торган ул. Санаторийга ялга барып кайттым, шул арада чир төшкән. Бакчада күбрәк үзем генә эшлим. Иптәшем Якуб казып бирә, анардан утырттырмыйм, ул утыртса бер нәрсә дә үсми, иң мөһиме комачауламый», – дип көлә Зөләйха апа. Үзенең кулы дөрестән дә җиңел, кайбер үсемлекләр өй алдында бетон арасында үсеп утыра, орлыклары коелып шунда чыккан икән. Зөләйха Минһаҗева файдалы үләннәргә дә урын биргән. Шалфей, бөтнек, календула үстерә, шулардан чәй ясый. Бакчачы үсемлекләр турында бик күп китаплар ала, мәгълүматны шуннан да туплый, интернеттан да өйрәнә, бакчачылар тәҗрибәсен дә куллана.

Бакчада матурлык өчен генә түгел, яшелчәләр, җиләк-җимешләр өчен дә урын бирелгән. Уңган бакчачының кыярлары инде Сабан туена өлгергән.

«Менә бу төзелеп киткән кура җиләген бер тамырдан үрчеттем. Урам ягындагы кура җиләген почта аша кайтардым, 10 данәгә заказ биргән идем, берсе генә исән иде. Әгәр терәү куйсаң ул 5 метрга кадәр җитә торган сорт. Очына кадәр җимеш бирә. Кар яуганчы җиләк бирә торганы да бар. Кура җиләгенең ботагын җиргә күмеп куям да, тамыр җибәргәч кисеп утыртам. Менә бу чүлмәкләрне сораучылар булса дип әзерләп куйдым. Быел чия белән черешня да күп булды. Менә монысы «войлочная вишня» дип атала. Ул тәлгәшләнми, ботакны сыдырып ала. Ап-ак чәчәккә күмелгән иде, аны махсус тәрәз каршына утырткан идем. Айва, груша, годжи җиләге дә утырттым, алмагачларым да бар. Тиздән ежемалина өлгерә. Бакчамда бөтен нәрсә бар инде минем, кара миләш белән абрикос кына утыртасым бар әле, урыннарын әзерләп куйдым», – ди Зөләйха апа. Бакчага, җир эшенә мәхәббәт нәселдән килә ди ул үзе. Әти-әнисе гомер буе бакча тоткан, мул уңыш алган.

Үсемлекләрне утырту гына түгел, дөрес тәрбия дә кирәк. Аларга һәрдаим ашлама кертеп торырга кирәк. «Компост та ясыйбыз, башкасын да сибәм, кайчакта ипине дә җебетеп салам, ашарга ярата алар», – дип аңлатты Зөләйха Минһаҗева.

Бакчаның бер почмагында кухня (җәен гаилә шунда ашый, пешерә), таган да бар. «Бу минем иң яраткан урын. Вакыт булганда шунда утырып китаплар укыйм. Тик менә вакыт кына бик җитми, әмма вакыт табылыр әле», – дип хыяллана бакчачы.